МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 апрель 2019 ел №М 167

Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында» 2017 елның 11 августындагы М 327 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе 1 бүлегенең 3 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында» 2017 елның 11 августындагы М 327 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне «сәяси партиядән» сүзләреннән соң «һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 1 пунктны «сәяси партиядән» сүзләреннән соң «һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

3) кушымтада:

- нигезнамәнең исемен «сәяси партиядән» сүзләреннән соң «һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

- 1 пунктны «сәяси партиядән» сүзләреннән соң «һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан» сүзләре белән тулыландырырга, «бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 5 пунктны «сәяси партиядән» сүзләреннән соң «һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан» сүзләре белән тулыландырырга;

4) нигезнамәгә 1 нче кушымтаны 1 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

5) нигезнамәгә 2 нче кушымтаны 2 нче кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андрееваga, Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллинга, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Андреева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

үрнәк

__________________________________________

__________________________________________

җирле үзидарә органы җитәкчесенең вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары

__________________________________________

__________________________________________

муниципаль хезмәткәр вазыйфасының исеме, фамилиясе, исеме һәм атасының исеме

Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында
гариза

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ санлы Федераль законның 14 маддәсе 1 бүлегенең 3 пункты нигезендә, миңа бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуны, коллегиаль идарә органнары составына керүне рөхсәт итүегезне сорыйм (кирәк булмаганын сызарга яки бетерергә)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________.

(коммерцияле булмаган оешма турында, муниципаль хезмәткәр башкарырга ниятләнгән эшчәнлек турында мәгълүматларны, кем буларак, тиешле эшчәнлекне башкара башлауның күздә тотылган датасын, башкаларны күрсәтергә)

____________________ ____________________

(дата) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

үрнәк

Бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм профессиональ союз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында гаризаларны теркәү журналы

| Т/с | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и. | Гариза биргән муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасы | Кадрлар хезмәтенә гариза керү датасы | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең Ф.И.А.и. | Гаризаны кабул иткән муниципаль хезмәткәрнең имзасы | Гаризаның күчермәсен алганда муниципаль хезмәткәрнең имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |